*Мөхтәрәм, мөселман кардәшләр!.. Әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү!*

*Барлык мактауларыбыз безне бүген бергә җыйган Аллаһу Сөбеханәһү вә Тәгаләгә булсын! Безне Япониягә, мәшһүр татар дин галимнәре гизгән, Ислам тараткан шушы илгә чакыручыларга Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре яусын!*

*Сезгә Русия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, Русия Мөфтиләр шурасы җитәкчесе, мөфти шәех Равил хәзрәт Гайнетдиннең һәм барча Русия мөселманнарының ихлас сәламен китердем! Әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү!*

Мәгълүм ки, мәшһүр исламият укымышлысы, күренекле җәмәгать эшлеклесе Рәшит казый Ибраһимның фикерләренә, 1909 (мең тугыз йөз тугызынчы) елда Япониягә килү нык тәэссир итә. Әмма моны (бу тәэссириятны) аңлау өчен, ул чорның вәзгыяте белән бергә, казыйның Русия империясендә яшәгән замандашлары фикерләрен дә күз алдына китерү зарур.

Егерменче йөз ел башында дөнья күләмендә бик күп халыклар үсеш юлы-тәррәккыять турында уйланды. Аурупалы акыл иясе Гегельнең өйрәтүләре өскә чыкты. Аның фикеренчә, илләр Көнбатыш Аурупаны кабатларга, аннан үрнәк алырга тиеш, яки тарих харитасыннан төшеп калырга мәҗбүр, иде. Азия, Африка өлкәләренең Аурупалылар тарафыннан идарә ителүе - ошбу фикернең хаклыгын раслый кебек күренә. Русия һәм Османлы дәүләтенең кайбер җитәкчеләре, сәясәтчеләре дә, нигездә, Гегельнең өйрәтүләрен хуплады. Әйтик, 1905-1907 (мең тугыз йөз бишенче-җиденче) елдагы Русия инкыйлабы, 1908 (мең тугыз йөз сигезенче) елгы Яшь Төрек инкыйлабы абсолют монархияне конституцион монархиягә әйләндерү шигаре белән үтте. Индустриаль инкыйлаб, түнтәрелеш үткәрергә чакырдылар. Русиядә инде болар өчен шартлар җитешкән иде. Чөнки эшчеләр хәрәкәте куатләнгән иде. Нәтиҗәдә тарихка 1917 (мең тугыз йөз унҗиденче) елның Октябрь революциясе язылды.

Егерменче гасыр башында Русиядә яшәүче мөселманнар Русиянең гомуми тәррәкыяте һәм аерым мөселман өммәте тәррәкыяте хакында җитди төшенде. Мәсәлән, унтугызынчы гасыр ахырында фикер иясе Исмәгыйл Гаспралы Франция моделе тарафдары буларак беленде. Шуны да әйтергә кирәк, 1890 (мең сигез йөз туксанынчы елларда) Франция - Русиянең

Көнбатыш Аурупадагы төп сәяси һәм икътисади тарафдарына әверелгән иде.

Исмәгыйл Гаспралыны Йосыф Акчура, Фатих Кәрими кебек мәшһүр татар фикер ияләре куатләде. Шул ук вакытта, кайбер дин галимнәре Аурупа казанышларын үзләштергәндә, милләтнең рухи кыйммәтләрен саклап калу кирәклеген аңлады. Бу юнәлештә олуг дин әһеле, мәгърифәтче Рәшит казый Ибраһим төп эшне алып бара. Ул Русия мөселманнары иҗтимагый-сәяси хәрәкәте башында тора. 1904 (мең тугыз йөз дүртенче) елның көзендә Идел-Урал, Әзербайҗан, Кырым, Төньяк Кавказ, Казахстан, Урта Азия, Себер мөселманнарын берләштерүдә көч куя.

Соңрак илдә бер-бер артлы мөселман өммәтен кузгаткан вакыйгалар була. 1905-1906 (мең тугыз йөз бишенче-алтынчы) елларда өч мәртәбә Бөтенрусия мөселманнары корылтае уздырыла, “Иттифак әл-мөслимен” Бөтенрусия мөселман фиркасе оештырыла, Русия Дәүләт Думасы мөселман депутатлары Мөселман фракциясенә берләшә.

1905 (мең тугыз йөз бишенче) ел ахырында Петербургта кыю сүзле “Өлфәт” (“Дуслык) гәзите дөнья күрә башлый. Рәшит казый әлеге гәзитнең нәшире һәм мөхәррире. 1906 (мең тугыз йөз алтынчы) елның апрель-июль айларында, Беренче Дәүләт Думасы чакырылышы вакытында, гәзиттә Ислам дөньясын берләштерү, милли автономияләр кирәклеге турында фикерләр языла.  Рәшит казый, нәкъ менә шул көннәрдә, төрле милли төркемнәрнең сәяси карашларын, хәлләрен ныклап өйрәнә. 1907 (мең тугыз йөз җиденче) елның өченче июнендә, Икенче Дәүләт думасы таратыла. Чөнки думада күпләр, ул дәвернең иҗтимагый тәртипләре белән килешми. Дума таратылгач Русиядә реакцияләр, болганышлар чоры башлана.

9 июньдә “Өлфәт” гәзите чыгудан туктатыла. 1908 нче елда Үзәк Комитет һәм “Иттифак”ның Казан бюросы лидерлары, мөхтәрәм татар затлары Галимҗан Баруди, Габдулла Апанай сөргенгә җибәрелә.

Йосыф Акчура 1908 елның августында Казаннан Истанбулга юл тота. Аңа кадәр «Өченче июнь вакыйгаи мөәссәфәсе» дип аталган китабын нәшер итә. Китабында 3 (өченче) июнь вакыйгасын, 1907 (мең тугыз йөз җиденче) елгы дәүләт түнтәреше дип, бәяли. Русиянең Аурупа дәүләтләре үрнәгендә алга китешенә нокта куелганын әйтә.

Рәшит хәзрәт Ибраһим, шулай ук, китү карарын кабул итә. Сигезенче (1908) елның сентябрь аеннан алып, тугызынчы (1909) ел башына кадәр Петропавлов, Томск, Иркутск, Чита, Харбин, Владивосток шәһәрләрендә туктала, татар мөселманнар белән аралаша.

Унсигез (18) гыйнварда Рәшит казый Владивосток шәһәрендә лиманга (пароходка) утырып Япониягә кузгала. Шуны да искә төшереп китү урынлы булыр, аның туган җире - Себердәге Тубыл губернасындагы Тара каласы. Әлеге шәһәр, уналтынчы гасырда, Себер ханлыгы чорында ук мөһим Ислам үзәге буларак танылган җир.

Казый Японияне беренче мәртәбә 1902-1903 (мең тугыз йөз икенче – өченче) елларда күргән. Әмма Русия консуллыгы таләбе белән, Япониядән җибәрелгән. Тугызынчы елда исә, кире әйләнеп кайта. Шул елны кыштан җәйгә кадәр японнар тормышы турында җентекләп яза. Иң беренче чиратта Токиядә яшәгәннәрен сурәтли.

Япониягә сәяхәте уңаеннан язылган мәкаләләре “Дәүре галәм” (“Дөнья әйләнү”) исеме белән Казанда “Бәянелхак” гәзитендә басылып бара. Мәкаләләрендә Русия бары руслар иле генә түгел икәнен күрсәтә. Себердә исә, татарлар, якутлар, бурятлар яшәвен, төрле диннәрне тотуларын яза. Улан-Удэда җирлектәге хамбо-лама дин әһеле белән күрешүен тасвирлый.

Шунысы ачык, Рәшит казый Япониядә, Русия һәм Госманлы империяләрендәге каршылыклы вәзгыятьне истә тоткан хәлдә, тәррәкыять өчен уңай бер үрнәк эзли. “Дәүре галәм”не аерым бер китап рәвешендә түгел, ә “Бәянелхак” гәзите битләреннән, Русия хәбәрләре һәм Османлы мәгълүматлары белән беррәттән уку кызыклы. Казыйның бөтен мәгълүматларына аерым-аерым тукталып тору кирәкмәс. Аның гомуми күзаллауларын аңларга тырышыйк.

Рәшит казый игътибар биргән беренче сәяси вакыйга – Япониядә 1889 (мең сигез йөз сиксән тугызынчы) елда кабул ителгән Конституциянең 20 еллыгын бәйрәм итү. Монда ул, көчле хаким җитәкләгән Конституцион дәүләт кору идеясенә тугъры калуын ассызыклый. Шул ук вакытта, фән - мәгариф үсешенә басым ясый. Аларны гомуми тәррәкыять белән бәйләп карый. Башка җәдитчеләрдән аермалы буларак, аурупалыларның әхлакый йөзен, гомумән, Аурупа культурасын һәм яшәү рәвешен өнәми. Аларны таркаулыкта, өлкәннәрне, бер-берсен хөрмәт итмәүдә гаепли. Тамырларыннан ераклашулары өчен тәнкыйть итә. Япон җәмгыятендәге

бердәмлек һәм үзара ярдәмләшүне өстен күрә. Японнарның бердәмлеген аурупалыларның индивидуализмына кара-каршы куя.

Хәзрәт маркиз Ито сүзләрен китерә. Ул: “Японнар мәдәниятне Һиндстаннан һәм Кытайдан, ә гыйлем һәм фәнне - Аурупадан алган”, - дигән имеш. Рәшит казый Японнарның Аурупа культурасына таянмавын һәм хәтта Аурупа юнәлешендәге югары уку йортларында япон киемен киеп йөрүләрен кат-кат ассызыклый. Монда Османлы империясенең мәгариф министры Мөниф Пашадан ишеткән гыйбарәне кабатлый: “Аурупа мәгарифен кертү өчен, аңар мөселман киемен кидерергә кирәк”.

Японияне анализ иткән Рәшит казый, асылында, модерн милли дәүләтнең оешмаларына игътибар юнәлтә. Университетларны, мәктәпләрне, нәшриятләрне, китапханәләрне, музейларны, театрларны, госпитальләрне сурәтли. Музей, бер үк вакытта, кылыч, туп, тәңкә, фарфор коллекцияләре белән бергә, милли хәтерне саклау вазыйфасын башкара.

Ул заманча (модерн) индустриаль җәмгыятьне сурәтли, шуңа күрә хатын-кызлар турында да сүз итә. Ул вакытларда, Русия Империясенең бер өлеше булган, Финляндия Бөек кнәзлегендә хатын-кызлар болай да тавыш бирү хокукын ала.

Русия империясендә исә, 1906 (мең тугыз йөз алтынчы) елда бөтен кешеләргә тигез хокук бирү турындагы матдә “Иттифак” программасына кертелгән иде. Әмма тигез хокук мәсьәләсе каршылыклы фикерләр уята. Болар белән якыннан таныш Рәшит казый, Япониядә хатын-кызлар хокукы турында чакырулар юк, дип яза. Япон хатыннарының, гадәттә, гаилә тормышына юнәлгәнен күрсәтә. Ләкин, белем алуларын, телефон-телеграф операторы, тимер юлда кассир булып эшләүләрен яза. Үзенең хатын-кыз гәзитәче белән аралашуын да әйтә.

Гомумән, егерменче гасыр башында Русия җәмгыятенең, мөселманнар голәмәсенең тәрәккыят, яңарыш, модернизация юллары барланды. Шул сәбәпле, төрле дәүләтләрнең тәҗрибәсе өйрәнелде. Әйтик, Рәшит казыйның иң якын замандашы, мәшһүр исламият галиме Муса Җаруллаһ Биги, Финляндиядәге тигез иҗтимагый хокукка ия протестант җәмгыятен үрнәк итеп күрде. Әмма Рәшит казыйга, Аурупа технологиясен һәм мәгарифен үзләштергән Япония бик нык йогынты ясый. Милли культураларын һәм рухи нигезләрен саклаулары сокландыра.

Шул да үзенчәлекле, бер яктан, Япония Рәшит казыйның карашларына тәэсир ясаган. Икенче яктан, ул үзе Япониянең интеллектуаль культурасына зур өлеш кертә. Мәгълүм ки, күренекле япон ислам галиме Тосихико Идзуцуның ике остазы булган. Аларның берсе Габдрәшит Ибраһим, икенчесе Муса Биги. Икесе дә татар, ана телләре – төрки тел.

Танылган япон галиме гомеренең соңгы елларында аларның икесе хакында да җылы, якты хатирәләрен уртаклаша. Ачыктан-ачык бу ике татар-төрек галиме исемнәрен зекер итә, алар ярдәмендә исламиятне өйрәнүен аңлата.

Менә боларны искә төшерә.

Беркөн Ибраһим хәзрәт, кулындагы иске китапны күрсәтеп: "Бу китап әле генә Америкадан килде,” – дип, гарәпчә сөйләшә. Егет, күптәннән өйрәнергә хыялланган классик, камил гарәп телен ишетүдән бик бәхетле була. Хәзрәт аның гарәпчә өйрәнергә теләвен хуплый. Әмма гарәпчәне бары тик гарәп теле буларак өйрәнүнең бернинди мәгънәсе юклыгын әйтә. Ислам теле буларак, аны Исламият белән берлектә өйрәнү кирәклеген аңлата. Атнага бер тапкыр дәрескә килергә тәкъдим итә, егет көн саен диярлек йөри. Ике еллап сабак ала. Тора-бара Рәшит хәзрәт япон егетен бик якын күрә. “Син тумыштан мөселман, шул сәбәплә син минем **улым**”, - дип, әйтә торган була.

Беркөн хәзрәт егетне мәчеткә алып бара. Бөек галим килүен хәбәр итә. Рәшит хәзрәт утыз сигезенче (1938) елда Тосихико Идзуцуны мәшһүр Муса Бигиев белән таныштыра.

Тосихико Идзуцу “доктор Мусса” дип атаган кеше, чын мәгънәсендә даһи зат. Ифрат киң карашлы илаһият галиме-теолог һәм ислами хокук белгече Муса Биги Идзуцуга гарәп телен өйрәтә, дини гыйлем бирә.

Соңыннан япон Ислам галиме, мөгаен, Муса Биги сабакларына һәм үзенең тәҗрибәсенә таянып, гарәп теле дәреслеген язгандыр да. Шушы рәвешле, японнарның Исламны өйрәнүләрендә Русия мөселманнары төп урынны алып тора.

Әлбәттә, бу интеллектуаль бәйләнеш җепләре җентекләп өйрәнүне көтә. Үтмештәге олуг галимнәребезнең шәхсиятләрен, хезмәтләрен әтрафлы өйрәнү, хакыйкый күзаллау әһәмиятле. Хәзерге заманда, янә Көнбатыш моделеннән ваз кичү бара, бүгенге шартларда дин әһелләребезнең милли һәм дини нигезләрне саклау тәҗрибәсен яңадан өйрәнү тагын да мөһим.

*Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә барыбызга да көч-куат, ныклык бирсен, гамәлләребезне уң кылсын! Тыңлавыгыз өчен рәхмәт яусын!*